**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 12 май № 279

г. Казань

Татарстан Республикасы территориясендә терлекләрне һәм терлекчелек продуктларын алу турында

«Ветеринария турында» 1993 ел, 14 май, 4979-1 нче Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә терлекләрне һәм терлекчелек продуктларын алу турында» 2006 ел, 26 май, 310 нчы карары (алга таба – Кагыйдәләр) нигезендә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә терлекләрне һәм терлекчелек продуктларын алуны үткәрү ихтыяҗы турында 2017 елның 11 маендагы 1963-вх номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы барлыкка килүне булдырмау һәм аның чыганакларын бетерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Лаеш районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2017 ел, 10 май, ПУ-372 нче Указының 1, 3 нче пунктларында билгеләнгән территориядә терлекләрне һәм терлекчелек продуктларын алуны үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә:

әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән чараларны үтәүне оештырырга;

терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә терлекләрне һәм терлекчелек продуктларын алуны үткәрү өчен билгеләнгән тәртиптә махсус комиссия төзергә;

алда әйтелгән комиссия катнашында терлекләрне һәм терлекчелек продуктларын алуны үткәрергә һәм Кагыйдәләргә теркәлгән 2 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча акт белән рәсмиләштерергә;

Россия Федерациясе Баш дәүләт ветеринария инспекторы раслаган 1995 елның 4 декабрендәге 13-7-2/469 номерлы Биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юк итү буенча ветеринария-санитария кагыйдәләре нигезендә алынган терлекләрне һәм терлекчелек продуктларын юк итүне оештырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\279.doc